ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 188-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 188-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе
вазыйфаларын башкаручы М.Г. Әхмәтов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре
2026 елның 22 июле
№ 663-VII ДС

проект

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты
тарафыннан кертелә

**«Оешмалар мөлкәтенә салым турында»**
**Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 5 статьяларына**
**үзгәрешләр кертү хакында**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» 2003 елның 28 ноябрендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (2010 елның 5 июлендәге 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 11; 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 5, № 8 (I өлеш); 2012, № 2, № 6 (I өлеш); 2013, № 3, № 6 (II өлеш), № 10, № 12 (I өлеш); 2014, № 10 (I өлеш); 2015, № 6 (I өлеш), № 8 – 9; 2016, № 1 – 2, № 6 (III өлеш); Татарстан Республикасы законнары җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2017, № 1 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 50 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 36 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 34 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 90 (I өлеш); 2023, № 48 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 73 (I өлеш); 2024, № 45 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2025, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 74 (I өлеш), № 93; 2026, № 16 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяда:
а) 2 өлешнең 15 пунктында «оешмалар» сүзе алдыннан «Татарстан Республикасында халыкка табигый газ сата торган» сүзләрен өстәргә;
б) түбәндәге эчтәлектәге $3^3$ өлешне өстәргә:
«$3^3$. Татарстан Республикасында халыкка табигый газ сата торган оешмалар тарафыннан салымның исәпләнгән суммасыннан 72,73 процент күләмендәге салым түләнә, – газ бүлү челтәренең газүткәргечләренә карата, әлеге статьяның 2 өлешендәге 15 пунктында күрсәтелгән мөлкәт объектларыннан тыш.»;

2) 5 статьяда:
а) 10 пунктта «2027 елның 1 гыйнварыннан» сүзләрен «2028 елның 1 гыйнварыннан» сүзләренә алмаштырырга;

б) 12 пунктта «2027 елның 1 гыйнварыннан» сүзләрен «2032 елның 1 гыйнварыннан» сүзләренә алмаштырырга;

в) түбәндәге эчтәлектәге 17 пунктны өстәргә:

«17) 2032 елның 1 гыйнварыннан әлеге Законның 3 статьясындагы $3^3$ өлешен.».

**2 статья**

Әлеге Закон 2027 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Оешмалар мөлкәтенә салым турында»**
**Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 5 статьяларына**
**үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проектына**

# АҢЛАТМА

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проекты оешмалар мөлкәтенә салым буенча салым түләүчеләрнең аерым категорияләре өчен билгеләнгән салым ташламаларының гамәлдә булуын озайтуны күздә тота.

Бакчачылык яисә яшелчәчелек коммерциягә карамаган ширкәтләренә, шулай ук гражданнар тарафыннан бакчачылык, яшелчәчелек яисә дача хуҗалыгы алып бару өчен 2019 елның 1 гыйнварга кадәр төзелгән коммерциягә карамаган оешмаларга карата гомуми файдаланудагы мөлкәт булып торган мөлкәткә карата салым салудан азат ителүне 2028 елның 1 гыйнварына кадәр озайту каралган. Салым ташламасы социаль була һәм бакчачылык һәм яшелчәчелек ширкәтләрен үстерүгә юнәлдерелгән.

Сәламәтлек саклау, физик культура һәм спорт ихтыяҗлары өчен файдаланыла торган социаль-мәдәни өлкә объектларына карата оешмалар өчен, федераль бюджеттан, Татарстан Республикасы бюджетыннан һәм җирле бюджетлардан финанслана торган оешмалардан тыш, халыкның медицина ярдәме сыйфатыннан канәгатьлеген арттыру һәм халыкның системалы рәвештә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүче өлешен арттыру максатларында, исәпләнгән салым суммасының 4,55 проценты күләмендә салым түләү рәвешендә билгеләнгән преференцияне 2028 елның 1 гыйнварына кадәр озайту каралган.

Татарстан Республикасында халыкка табигый газ сата торган оешмалар өчен, Россия Федерациясе Хөкүмәте актлары нигезендә Татарстан Республикасы территориясендәге торак пунктларда газ китерү чараларын гамәлгә ашыру кысаларында 2022 елның 1 гыйнварыннан яңа гына файдалануга тапшырылган 1,2 МПа кадәр, шуны да кертеп, басымлы газ бүлү челтәренең газүткәргечләренә карата закон проектында преференцияне исәпләнгән салым суммасының 4,55 проценты күләмендә салым түләү рәвешендә 2032 елның 1 гыйнварына кадәр озайту каралган.

Шулай ук закон проекты тарафыннан 2027 – 2031 елларга Татарстан Республикасында халыкка табигый газ сата торган оешмалар өчен исәпләнгән салым суммасының 72,73 проценты күләмендә салым түләү рәвешендә ташлама билгеләү тәкъдим ителә, – газ бүлү челтәренең калган газүткәргечләренә карата.

Әлеге чаралар газ бүлү оешмаларына салым йөкләнешен киметүгә һәм Татарстан Республикасында газлаштыруны алга таба үстерү өчен уңай шартлар тудыруга юнәлдерелгән.

**«Оешмалар мөлкәтенә салым турында»**
**Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 5 статьяларына**
**үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын**
**кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчен югалткан дип танылырга, туктатылып**
**торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан**
**Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**
**ИСЕМЛЕГЕ**

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын үз көчен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яки кабул итүне таләп итми.

**«Оешмалар мөлкәтенә салым турында»**
**Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 5 статьяларына**
**үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына**
**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

Бакчачылык һәм яшелчәчелек коммерциягә карамаган ширкәтләренә һәм сәламәтлек саклау, физик культура һәм спорт ихтыяҗлары өчен файдаланыла торган социаль-мәдәни өлкә объектларына карата социаль преференцияләр суммасы якынча 243,3 млн сум дип бәяләнә.

Россия Федерациясе Хөкүмәте актлары нигезендә Татарстан Республикасы территориясендәге торак пунктларны газлаштыру чараларын гамәлгә ашыру кысаларында 2022 елның 1 гыйнварыннан яңа гына файдалануга тапшырылган 1,2 МПа кадәр, шуны да кертеп, басымлы газ бүлү челтәренең газүткәргечләренә карата биш ел эчендә салым преференңияләре суммасы 807,5 млн сум күләмендә дип, газ бүлү челтәренең башка газүткәргечләренә карата – 928,3 сум күләмендә дип бәяләнә.